СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.04.2024 Баулы шәһәре № 246

Баулы муниципаль район Советының
2017 елның 12 маендагы 107 номерлы
«Баулы муниипаль районы Башкарма
комитеты турында Нигезләмәне раслау
турында» карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы Федераль законга, «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-сәламәтләндерү җирлекләре һәм курортлары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында», Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану» турында 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының 2017 елның 12 маендагы 107 номерлы «Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмәсенә» карарына (Баулы муниципаль район Советының 2019 елның 16 октябрендәге 225 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 277 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге 35 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

3.2. пунктының 23 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге аеруча саклана торган табигый территорияләрне саклау һәм куллану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

4.4.пунктын э) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«э) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый һәм муниципаль район милкендәге җир участоклары чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыра.»;

4.7. пунктының к) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча авылара характердагы чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

4.10. пунктының л) пунктчасын «, шулай ук су объектларын рекреацион максатларда куллану кагыйдәләре.» сүзләре белән тулыландырырга.

2. 1 пунктның икенче абзацы 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров